ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**«_18_» _гыйнвар_ 2018 ел** **№ _24_**

**"2018-2020 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы балаларына һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү»муниципаль программасын раслау турында**

Россия Федерациясенең «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1."2018-2020 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы балаларына һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү»муниципаль программуасын расларга.

2.«Арча муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУнә чираттагы финанс елына бюджет формалаштырганда программаны гамәлгә ашыру срокларын исәпкә алып, Программа нигезендә чараларны финанслауга ассигнованиеләр кертүне күздә тотарга.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш. http://arsk к tatarstan.ru.http://arsk

Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Р.И. Гарифҗановка йөкләргә.

Җитәкче И.Ә.Галимуллин

Башкарма комитетның

«___» ________2018 ел № ____
карары белән расланды

**"2018-2020 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы балаларына һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү»**
**муниципаль программасы**

ПРОГРАММАНЫҢ ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | Муниципаль программасы<br>"2018-2020 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы балаларына һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү» |
| Программаны эшләү өчен нигезләр | "2018-2020 елларга Татарстан Республикасы Арча районы башкарма комитеты, балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү" программасы Россия Федерациясе гражданнарын патриотик тәрбияләү концепциясе, Татарстан Республикасы балаларына һәм яшьләренә патриотик тәрбия бирү концепциясе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 24 июнендәге 424 номерлы карары белән расланган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы яшьләренә патриотик тәрбия бирү» ярдәмче программасы нигезендә эшләнде. |
| Программаның төп эшләүче | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| Программаның төп чараларын үтәүчеләр (килешү буенча) | Балаларны һәм яшьләрне патриотик тәрбияләү буенча координацион совет ,<br>Райвоенкомат<br>"Арча муниципаль районы мәгариф идарәсе" МУ,<br>Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге<br>"Арча муниципаль районы мәдәният идарәсе" МУ<br>Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлеге,<br>Ветераннар оешмалары Советы,<br>Социаль яклау бүлеге<br>«Арча үзәк район хастаханәсе» ДАССУ<br>«Татмедиа» ААҖ филиалы<br>Белем бирү учреждениеләре,<br>иҗтимагый оешмалары,<br>Арча муниципаль районы "Форпост" яшьләр үзәге " МБУ<br>РОСТО (ДОСААФ),<br>Конфесссия вәкилләре. |

| | |
|---|---|
| Программаның максатлары | -яшьләрдә иң мөһим рухи-әхлакый һәм социаль кыйммәтләр буларак гражданлык һәм ватанпәрвәрлекне үстерү;<br>-районда балаларда һәм яшьләрдә иҗтимагый тотрыклылыкны тәэмин итә торган патриотик тәрбия бирү системасын үстерү;<br>-яшьләрне армиядә хезмәт итәргә әзерләү;<br>- балаларның һәм яшьләрнең сәламәтлеген ныгыту, ялын һәм мәшгульлеген оештыру;<br>-патриотик тәрбия өлкәсендә иҗтимагый хәрәкәтне торгызуга һәм үстерүгә ярдәм итү;<br>-балалар һәм яшьләр арасында социаль-тискәре күренешләрне профилактикалау. |
| Программаның бурычлары | - балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү өлкәсендә ведомствоара координация системасын булдыру;<br>-патриотик тәрбия өлкәсендә районда бүлекләрнең, ведомстволарның иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итү;<br>-мәгариф учреждениеләрендә, өстәмә белем бирү учреждениеләрендә, иҗтимагый берләшмәләрдә патриотик тәрбиянең сыйфатын арттыру;<br>-патриотик тәрбия бирүнең норматив хокукый һәм оештыру-методик базасын үстерү; |
| Программаны гамәлгә ашыру сроклары | 2018 - 2020 еллар |
| Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Программа Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетының агымдагы акчалары исәбеннән финанслана<br>2018 ел- 100 мең сум<br>2019ел- 100 мең сум<br>2020 ел- 100 мең сум<br>Искәрмә: финанслау күләмнәре фараз характерында һәм, район бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш. |
| Программаны гамәлгә ашыруның көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре (Программаның нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары) | -хәрби-патриотик юнәлештәге оешмаларда балалар һәм яшьләр санын арттыру;<br>- балаларны һәм яшьләрне патриотик юнәлештәге чаралар белән җәлеп итүне арттыру; - яшьләрне армия хезмәтенә әзерләү буенча эшне камилләштерү.;<br>-сәламәтләндерү лагерьларында хәрби-спорт профильле патриотик сменалар санын арттыру;<br>- армиягә әзерлек узган яшьләр санын арттыру;<br>-патриотик тәрбия өлкәсендә белгечләр әзерләү;<br>-яшьләрнең рухи-әхлакый культурасы дәрәҗәсен күтәрү;<br>- Ватанны саклау буенча бурычларны үтәүгә әзерлек дәрәҗәсен күтәрү;<br>- яшьләрне армия хезмәтенә әзерләү эшен камилләштерү. |

## I. Кереш

"2018-2020 елларга Татарстан Республикасы Арча районы башкарма комитеты, балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү" программасы Россия Федерациясе гражданнарын патриотик тәрбияләү концепциясе, Татарстан Республикасы балаларына һәм яшьләренә патриотик тәрбия бирү концепциясе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 24 июнендәге 424 номерлы карары белән расланган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы яшьләренә патриотик тәрбия бирү» ярдәмче программасы нигезендә эшләнде.

Гражданнарның барлык социаль катламнарына һәм яшь төркемнәренә юнәлдерелгән программа район гражданнарының Ватанга хезмәт итәргә әзерлеген формалаштырырга мөмкинлек бирә торган гражданнарны патриотик тәрбияләү системасын үстерүнең төп юлларын билгели. Шул ук вакытта җәмгыятебезнең тәҗрибәсе һәм казанышлары, хәзерге заман чынбарлыгы һәм проблемалары, үсеш тенденцияләре исәпкә алына.

## II. Программаның максатлары һәм бурычлары

Программаның төп максаты - патриотик тәрбия системасын камилләштерү, үсеп килүче буында югары патриотик аң формалаштыру, Ватанга тугрылык булдыру, конституцион бурычларны үтәүгә әзерлек.

Бу максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:

-патриотик тәрбия системасын булдыруны дәвам итәргә;

-патриотик тәрбиянең норматив-хокукый һәм оештыру-методик базасын камилләштерүне дәвам итәргә;

-патриотик тәрбия бирүдә катнашуга иҗтимагый оешмаларны (берләшмәләрне), хезмәт коллективларын, аерым гражданнарны киңрәк җәлеп итәргә;

-мәгариф учреждениеләрендә, өстәмә белем бирү учреждениеләрендә, иҗтимагый берләшмәләрдә патриотик тәрбиянең сыйфатын үстерергә;

-яшьләр аңында патриотик кыйммәтләр, карашлар һәм инанулар, районның, Татарстан Республикасының, Россия Федерациясенең мәдәни, тарихи үткәненә һәм традицияләренә хөрмәт формалаштырырга;

-яшьләргә хәрби-һөнәри юнәлеш бирергә, хәрби хезмәткә әзерләргә;

-патриотик тәрбияне фәнни һәм мәгълүмати тәэмин итәргә.

## III. Программаны тормышка ашыруның төп юнәлешләре

Программа чаралары комплексы барлык категория гражданнарга патриотик тәрбия бирүне күздә тота. Әмма программаның өстенлекле юнәлеше булып үсеп килүче буынга патриотик тәрбия бирү тора. Шул ук вакытта төп басым мәктәп, гаилә һәм иҗтимагый оешмалар (берләшмәләр) белән берлектә тәрбия эшчәнлеге үзәге булган белем бирү учреждениеләрендә эшләүгә ясала.

## IV. Программаны тормышка ашыруның көтелгән һәм соңгы нәтиҗәләре

- балаларның һәм яшьләрнең әхлакый потенциалын арттыру, гражданлык һәм ватанпәрвәрлеген үстерү;
- патриотик тәрбия системасын саклау, үстерү;
- ялның һәм мәшгульлекнең оешкан формалары белән колачланган балалар һәм яшьләр санын арттыру;
- балалар һәм яшьләр арасында җинаятьчелек дәрәҗәсен киметү;
- иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлеген активлаштыру

## V. ПРОГРАММАНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ МЕХАНИЗМЫ

Программаны гамәлгә ашыру механизмы аның дәүләт статусы белән билгеләнә һәм килеп туган сәяси, социаль һәм икътисадый шартларны исәпкә ала.

Программаны үтәүчеләр түбәндәгеләр:

Район хәрби комиссариаты

"Арча муниципаль районы мәгариф идарәсе" МУ

"Арча муниципаль районының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге»

"Арча муниципаль районы мәдәният идарәсе" МУ

Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлеге

Ветераннар оешмалары Советы

Халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәге

Халыкны  эш белән тәэмин итү үзәге

«Арча РҮХ» ДАССУ

Форпост

«Татмедиа» ААҖ филиалы

Белем бирү учреждениеләре

РОСТО ДОСААФ

## VI. Финанслау

2018-2020 елларга Программа чараларын тормышка ашыруга якынча чыгымнар-300 мең сум-район бюджетыннан, шул исәптән: 2018 елга-100 мең сум, 2019 елга-100 мең сум, 2020 елга-100 мең сум.

**балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү» программасын гамәлгә ашыру чаралары планы 2018-2020 елларга Арча муниципаль районында**

| № т/б | Чаралар | Башкаручы | Үтәү срогы | Белешмә, финанслау чыганагы | Еллар буенча чыгымнар суммасы (мең сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2018 ел | 2019 ел | 2020ел |
| 1. | **Программаны үтәү буенча оештыру чаралары** | | | | | | |
| 1.1 | Хокук бозуларны профилактикалау буенча ведомствоара комиссия утырышларын уздыруны тәэмин итү | Ветераннар советы, РВК, Мәгариф идарәсе, ОДМСиТ | кварталга 1 тапкыр | - | - | - | - |
| 1.2 | Урта мәктәпләрнең, урта һөнәри уку йортларының укыту-методик һәм матди-техник базасын ныгыту. | мәгариф идарәсе, РВК, ГИБДД | даими | - | - | - | - |
| 1.3 | Туган як тарихы һәм милли традицияләр буенча түгәрәкләр төзү эшен дәвам итү | Мәгариф,мәдәният идарәсе | 2018-2020 | - | - | - | - |
| 2 | **Яшь гражданнарга патриотик тәрбия бирү өлкәсендәге эшчәнлекне камилләштерү** | | | | | | |
| 2.1 | Хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарның хәрби-исәпкә алу белгечлекләре буенча әзерлек | РВК, ДОСААФ | 2018-2020 | - | - | - | - |
| 2.3 | Уку-кыр җыеннары үткәрү | Мәгариф идарәсе, ОДМСиТ, РВК | ел саен | Агымдагы финанслау | 50 | 50 | 50 |
| 2.4. | Хәрби-патриотик тәрбия мәсьәләләре буенча массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре белән «түгәрәк өстәлләр» үткәрү | ММЧ | ел саен | - | - | - | - |
| 2.5 | Предприятиеләрнең, оешмаларның, учреждениеләрнең хезмәт коллективларын патриотик тәрбияләүдә катнашуга җәлеп итү | АМР башкарма комитеты,предприятие, организация, учреждение | даими | - | - | - | - |
| **3. Яшь буынны патриотик тәрбияләү чаралары** | | | | | | | |
| 3.1 | Армиягә алынучылар спартакиадасы | РВК, ОДМСиТ, "Форпост" үзәге | ел саен | Агымдагы финанслау | | | |
| 3.2 | Армиягә чакырылачак яшьләр белән оборона-масса һәм спорт чараларын үткәрергә | РВК, ОДМСиТ, "Форпост" үзәге | ел саен | - | - | - | - |
| 3.3 | Хәрби-патриотик тәрбия буенча ярышлар | РВК, "Форпост" үзәге | ел саен | Җирле бюджет | | | |
| 3.4 | Призывник көнен бәйрәм итү һәм бүләкләү | РВК, ОДМСиТ | апрель, октябрь | Агымдагы финанслау | 30 | 30 | 30 |
| 3.5 | Хәрби-гамәли спорт төрләрен үстерү | Мәгариф идарәсе, РВК, ОДМСиТ | 2018- 2020 | Җирле бюджет | | | |

| № т/б | Чаралар | Башкаручы | Үтәү срогы | Белешмә, финанслау чыганагы | Еллар буенча чыгымнар суммасы (мең сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2018 ел | 2019 ел | 2020ел |
| 3.6 | Бөек Ватан сугышы ветераннары, локаль сугышлар, тыл ветераннары белән очрашулар үткәрү | Мәгариф идарәсе, ветераннар Советы, Форпост үзәге | даими | - | - | - | - |
| 3.7 | Хәрби дан һәйкәлләрен карап тоту | Мәгариф идарәсе, иҗтимагый берләшмәләр | май-ноябрь | - | - | - | - |
| 3.8 | Хәрби каберлекләрне төзекләндерү эшләрен башкару өчен махсуслаштырылган студентлар отрядлары төзү | ОДМСиТ, ССУЗы, Центр Форпост | май | - | - | - | - |
| 3.9 | "Алга, яшь армиячеләр!" республика спорт уенында катнашу | Мәгариф идарәсе, | ел саен | Җирле бюджет | | | |
| 3.10 | «Аҗаган» хәрби-патриотик уены үткәрү | ОДМС, РВК, мәгариф идарәсе | ел саен | Агымдагы финанслау | 20 | 20 | 20 |
| 3.11 | Бөек Ватан сугышында Җиңү көненә, Россия хәрби дан көннәренә һәм истәлекле даталарга багышланган бәйрәм чаралары оештыру | Администрация, РВК, ветераннар Советы, иҗтимагый берләшмәләр | ел саен | Җирле бюджет | | | |
| 3.12 | Оборона-спорт айлыгы үткәрү | Мәгариф идарәсе | февраль | - | - | - | - |
| 3.13 | Китап күргәзмәләре, тематик сайлаулар, уку конференцияләре оештыру | Мәдәният идарәсе | ел саен | - | - | - | - |
| 3.14 | "Йолдызлык»республика конкурсында катнашу | ОДМСиТ, Мәдәният идарәсе | декабрь | Җирле бюджет | | | |
| 3.15 | Патриотик рухтагы кино-һәм видеофильмнар күрсәтү | мәгариф идарәсе Мәдәният идарәсе | даими | - | - | - | - |
| 3.16 | Бөек Ватан сугышы ветераннарына һәм инвалидларына, һәлак булганнарның тол хатыннарына һәм Бөек Ватан сугышында катнашучыларның үлгән хатыннарына, локаль сугышлар һәм конфликтларда катнашучыларга шефлык итү | Мәгариф идарәсе, волонтерлар | даими | - | - | - | - |
| 3.17 | Хәрби-гамәли спорт төрләре буенча хәрби хезмәткә чакырылучылар арасында ярышлар | РВК, ОДМСиТ | апрель, октябрь | Җирле бюджет | | | |
| 3.18 | Хәрби-патриотик, спорт, тарихи һәм туган якны өйрәнү юнәлешендәге махсус профильле лагерьларда катнашу | ОДМСиТ, Управление образования, РВК, Центр «Форпост» | ел саен | Җирле бюджет | | | |
| 3.19 | Балигъ булмаганнарның хокук бозуларын профилактикалау отрядларын камилләштерү чаралары | Мәгариф идарәсе, Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлеге | 2018-2020 | - | - | - | - |

| № т/б | Чаралар | Башкаручы | Үтәү срогы | финанслау ысулы, чыганагы | Еллар буенча чыгымнар суммасы (мең сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2018 ел | 2019 ел | 2020ел |
| 3.20 | "Ватан сагында" рәсемнәр конкурсы | Мәгариф идарәсе | гыйнвар-февраль | - | - | - | - |
| 3.21 | "Үлемсез полк" республика акциясендә катнашу | РВК, мәгариф идарәсе, - Администрация | 2018-2020 | - | - | - | - |
| 3.22 | Республика слетында, “Юнармия” бөтенроссия патриотик хәрәкәте парадында катнашу | Мәгариф идарәсе | май, октябрь | - | - | - | - |
| **4.** | **Патриотик тәрбия мәсьәләләре буенча гражданнарның иҗтимагый фикерен формалаштыру** | | | | | | |
| 4.1 | Район массакүләм мәгълүмат чараларында хәрби-патриотик тәрбия буенча иң яхшы материалга район конкурсын оештыру | ММЧ, мәгариф идарәсе | ел саен | - | - | - | - |
| 4.2 | Балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү буенча район газетасы битләрендә рубрикалар булдыру | Район газетасы | даими | - | - | - | - |
| 4.3 | Уку йортларында, предприятиеләрдә, җәмәгать урыннарында патриотик юнәлештәге күрсәтмә агитация стендлары урнаштыру | РВК, предприятиеләр администрациясе | 2018-2020 | - | - | - | - |
| | | | | **Барлыгы:** | **100,0 (бюджет) район)** | **100,0 (бюджет) район)** | **100,0 (бюджет) район)** |
| | | | | **БАРЛЫГЫ:** | **300,0 мең сум (район бюджеты)** | | |